**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2024-2025 уку елы) 7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 150 минут**
**Максималь балл – 45 балл**

**I. Тест биремнәре (10 балл).**

1. Халык авыз иҗаты жанрлары дөрес күрсәтелгән вариантны билгеләгез (1 балл):
1) бәет, нәсер
2) **дастан, бәет**
3) дастан, хикәя

2. Бер яки ике вакыйгага нигезләнеп иҗат ителгән, образлар саны күп булмаган кечкенә күләмле эпик жанр (1 балл):
1) повесть
2) поэма
3) **хикәя**

3. Әдәби әсәрдәге кеше образларының төренә карый (1 балл):
1) **җыелма**
2) күчерелмә мәгънәле
3) персонаж

4. Сюжет элементы (1 балл):
1) эчке каршылык
2) композиция
3) **төенләнеш**

5. Әдәби әсәрдә персонажның эчке дөньясын, ягъни фикерләрен, хис-кичерешләрен, теләк-омтылышларын матур әдәбиятка хас чаралар аша тулы итеп, җентекләп сурәтләү (2 балл):

Җавап: **психологизм**

6. «Акчарлаклар», «Буранда» әсәрләренең авторы (1 балл):
1) Галимҗан Ибраһимов
2) Габдулла Тукай
3) **Шәриф Камал**

7. Габдулла Тукайның әсәрләре генә урын алган рәтне билгеләгез (1 балл):
1) **«Милләтә», «Җәйге таң хатирәсе», «Милли моңнар», «Туган тел»**

2) «Кайсыгызның кулы җылы?», «Җәйге таң хатирәсе», «Милли моңнар»

3) «Милләтә», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә», «Милли моңнар»

8. *Бигрәк тә үзенә яхшы таныш булган сезонлы эшчеләр, шахтёрлар – бәхет эзләп чит җирләргә китәргә мәҗбүр булган татар халкының язмышын бөтен ваклыкларына кадәр белеп яза. Кеше күңеленең нечкәлекләрен аңлап, геройларының рухи халәтен психологик тирәнлектә ача алганлыктан, аның әсәрләреннән эчке бер моң сирпелеп тора. Ул кыска итеп, аз сүз белән тирән мәгънә җиткерә белә. Шуның белән XX гасыр башы әдәбиятын яңа тема, үзенчәлекле геройлар, сәнгатьчә сурәтләү алымнарына баета*. Кем турында сүз бара? (2 балл):

Җавап: **Шәриф Камал**

**II. Язма җавапка бәйле биремнәр (25 балл).**

1. Лиро-эпик жанр буларак поэма. Поэма жанрына хас үзенчәлекләр (10 балл).

Мисал өчен:

**Лиро-эпик жанр атамасы, сюжет сызыклары лирик чигенешләр, хис-кичереш һәм мөнәсәбәт белдерү белән үрелеп бара, әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләр күтәрелә торган әсәр. Поэма жанры лирик һәм эпик башлангычларның үзенчәлекле синтезын тәшкил итә. Анда сурәтләнгән вакыйгалар сюжетны – эпик катламны барлыкка китерә, зур вакыйгалар кайчакта берничә сызыгы тәшкил итәргә дә мөмкин, аларга бәйле төстә автор үзенең мөнәсәбәтен укучыга җиткерә. Лирик башлангычта исә сурәтләнгәннәргә шәхси мөнәсәбәт, автор-хикәяләүче яки лирик геройның хисләре, фикерлә¬ре, бәясе әһәмиятле роль уйный. Поэмада хикәяләүче һәм лирик герой сыйфатларын туплаган хикәяләүче-автор образы алга чыга һ.б.**

2. Ш.Камал иҗаты турында ниләр беләсез, аның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар? Үзенең әсәрләрендә автор нинди тема-проблемаларны күтәрә? Үзегез укыган бер әсәр мисалында аңлатыгыз (10 балл):

**7 сыйныф дәреслеге, 2014, Б. 47-48 (“Акчарлаклар” повестена бәйләп) яки яңа дәреслек (“Буран” хикәясенә бәйләп).**

3. Һ.Такташның «Мокамай» поэмасыннан алынган әлеге өзектә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып языгыз (5 балл):

*Белмим,*
*Әллә күпкә,*
*Әллә бик озакка,*
*Ахры, мәңге онта алмамын*

*Тамбов урманнары уртасында*
*Усак яфраклары шаулавын...*
*Алар мәңге минем хыялымда*
*Шаулый-шаулый яфрак ярырлар,*
*Карт имәннәр, калмый минем арттан,*
*Кая барсам, озатып барырлар...*
*Бер җирдә юк андый урманнар,*
*Бер җирдә юк камыш сабаклары –*
*Андагыдай шаулый торганнар...*

*Әкияттәге ике бала кебек,*
*Каен башларына үрмәләп,*
*Ике штансыз малай дөнья белән*
*Танышып йөргән идек бергәләп...*
*Беребез сары чәчле, беребез – кара:*
*Сары чәчлесе – ул мин идем;*
*Кара чәчле, коңгырт кара күзле,*
*Кәкре аяклы дустым, җанкисәгем,*
*Ул, Мокамай бәгърем, син идең....*

**Лексик чаралар (антоним), стилистик фигуралар (анафора, инверсия, риторик эндәш), троплар (чагыштыру, метафора, эпитет) һ.б.**

**III. Әдәби әсәргә анализ (10 балл).**

**Әсәрнең жанры – хикәя.**

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2024-2025 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 150 минут**
**Максималь балл – 45 балл**

**I. Тест биремнәре (10 балл).**

1. Халык авыз иҗаты жанрлары дөрес күрсәтелгән вариантны билгеләгез (1 балл):
1) табышмак, шигырь
2) **дастан, табышмак**
3) дастан, роман

2. Мәгърифәтче геройны үзәккә алган, аң-белем, тәрбия мәсьәләләре күтәрелгән әсәрләр (1 балл):
1) халык авыз иҗаты
2) мәгърифәтчелек
3) **мәгърифәтчелек әдәбияты**

3. Әдәби әсәрдә кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлау (1 балл):
1) образ
2) **портрет**
3) эпитет

4. Сюжет элементы (1 балл):
1) тышкы каршылык
2) хронотоп
3) **чишелеш**

5. Әдәби әсәрдә чагылган урын һәм вакыт бөтенлеге (2 балл):

Җавап: **хронотоп**

6. «Сүнгән йолдызлар», «Искәндәр» әсәрләренең авторы (1 балл):
1) Гадел Кутуй
2) **Кәрим Тинчурин**
3) Шәриф Камал

7. Гадел Кутуй әсәрләре урын алган рәтне билгеләгез (1 балл):
1) «Кораб», «Ана догасы»
2) «Бер хәрабәдә», «Әйтелмәгән васыять»
3) **«Тапшырылмаган хатлар», «Сагыну»**

8. *Искәндәр!*

*Хатымны дәвам итәм.*

*1923 ел иде. Казанда университет рабфагына укырга кердем…*

*Беренче дәресләрне тыңлау белән үк, мин бәхеттән, шатлыктан, нәрсәгә тотынырга белмичә, шашып йөри башладым. Рабфакка барганда да, кайтканда да бик еш: «Шушы урамнар, шушы коридорлар буйлап кайчандыр китап, дәфтәр тотып Ленин йөргән, шул бинада Толстой укыган. Шунда укырга дип, яшь Горький хыял корган. Шул бинадан дөньяның атаклы галимнәре чыккан. Мин укый торган бүлмәләрдә аларның да тавышлары яңгыраган», – дип уйлана башладым…* Әлеге өзек кайсы әсәрдән алынган? (2 балл):

Җавап: **«Тапшырылмаган хатлар»**

## II. Язма җавапка бәйле биремнәр (25 балл).

1. Әдәби төр буларак лирика. Лирик әсәрләргә хас үзенчәлекләр (10 балл).

Мисал өчен:

**Лирика кешенең халәтен, хисләрен, уйларын, кичерешләрен сурәтләү предметына әверелдерә. Лирикада билгеле бер моменттагы, вакыттагы нәфрәт, ачу, борчылу, кайгы, сагыш шатлык, сагыну кебек хисләр урын таба, бу хисләрнең тирән һәм күпкырлы сәбәбе ачыклана.**

**Лирика «мин» исеменнән сөйли, ләкин шул ук вакытта киң гомумиләштерүләр ясый. Шагыйрь үзе кичергән һәм кичерә торган халәт турында яза, шәхси хис һәм тойгыларга нигезләнә. Ләкин үзенең шәхси-кабатланмас дөньясын сурәтләү белән бергә, ул гомумәһәмиятле, яшәешкә хас булган, башка кешеләрнең хисләре белән тәңгәл кичерешләр турында сөйли. Лирик образ әдипнең күңел дөньясына, тормышны күрү, аңлау, кабул итү рәвешенә бәйле, шул ук вакытта шигырьдәге кичереш әдип яшәгән җәмгыять вәкилләренеке дә.**

**Психологизм беренче урында тора. Барлык детальләр дә психологик детальләр булып, пейзаж, портрет, әйберләр дөньясы да психологик вазифа башкара.**

**Лирик әсәр сюжетлы түгел, ләкин кайчакта сюжетка охшаш хис-кичереш үсеш-үзгәреше ачык күренеп тора. Сәбәп үзгәрү хисләрнең алышынуын, яки аларга төрле төсмерләр өстәлүне тәэмин итә. Төр композицион алымнарга таяна һәм һәрвакыт катлаулы төзелешле була.**

**Лирика төгәл, аһәңле сөйләүне сорый, анда һәр сүз аерым бер мәгънәви һәм эмоциональ көчкә ия булырга тиеш. Шуңа күрә лирика шигъри сөйләм аша бәян ителә. Бу сөйләмдә яңгыраш, ритм, образ – бар да әһәмиятле. Чөнки мәгънә сүзләр ярдәмендә генә белдерелми, бәлки әдәби төзелештә табыла. Образлылык читләтеп әйтүгә корылып, символик, аллегорик образлар, тел-сурәтләү чаралары күп була.**

2. Әмирхан Еники яки Фатих Әмирхан иҗаты турында ниләр беләсез? Берсен сайлап алып җавап языгыз. Аның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар? Үзенең әсәрләрендә әлеге автор нинди тема-проблемаларны күтәрә? Үзегез укыган бер әсәр мисалында аңлатыгыз (10 балл):

**8 сыйныф дәреслеге, 2015, Б. 75-76 (Ф.Әмирхан) яки яңа дәреслек (Ә.Еники)**

3. Нури Арслановның «Яз» шигырендә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып языгыз (5 балл):

*Матур чаклар!*
*Өстән энҗе тамып тора,*
*Ерганаклар,*
*Кар сулары агып тора,*
*Дымлы, салкын*
*Җирне нурга манып кына*
*Кояш алтын*
*Литаврасын кагып тора.*
*Китте кышлар*
*Мамык тунын салып кына,*
*Кайтты кошлар*
*Канатларын кагып кына,*
*Карда посып,*
*Умырзая калкып чыга,*
*Килсә гыйшык –*
*Урын калмый вак борчуга.*
*Тирәмдә ямь, –*
*Мин шул хәят тәмен беләм!*
*Шуңа сөям*
*Сезне җаным-тәнем белән.*

**Инверсия, риторик өндәү, метафора, сынландыру, эпитет һ.б.**

**III. Әдәби әсәргә анализ (10 балл).**

**Әсәрнең жанры – хикәя.**

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2024-2025 уку елы) 9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 180 минут**
**Максималь балл – 55 балл**

**I. Тест биремнәре (10 балл).**

1. Суфи идеяләрне алга куйган, илаһи мәхәббәт темасы күтәрелгән әсәрләр (1 балл):
1) суфичылык
2) дини әдәбият
3) **суфичылык әдәбияты**

2. Модернистик агым (1 балл):
1) **импрессионизм**
2) романтизм
3) реализм

3. Рун һәм уйгур язулы истәлекләр әдәбиятның кайсы чорына карый (1 балл):
1) Болгар чоры әдәбияты
2) халык авыз иҗаты
3) **гомумтөрки әдәбият**

4. Сюжет элементы (1 балл):
1) анафора
2) хронотоп
3) **пролог**

5. Әдәбиятны үсеш-үзгәрештә, үзенә хас закончалыклары булган процесс буларак өйрәнә торган фән (2 балл):

Җавап: **<u>әдәбият тарихы</u>**

6. Мөхәмәдъяр, Кол Шәриф иҗатлары әдәбиятның кайсы чорына карый (1 балл):
1) Алтын Урда чоры әдәбияты
2) **Казан ханлыгы чоры әдәбияты**
3) Болгар чоры әдәбияты

7. Мәүла Колый әсәрләренең жанры (1 балл):
1) **хикмәт**
2) кыйсса

3) дастан

8. *Җәдитчелек яшәешнең икътисад һәм сәясәт өлкәләренә дә тирән үтеп керә. Гомумән, әлеге җитди үзгәрешләр татар әдәбиятына да йогынты ясый. Мәгърифәтчелек, соңрак җәдитчелек идеяләре нәкъ менә матур әдәбият аша халыкка барып ирешә. Бу яктан сүз сәнгатенең вазифасы бермә-бер арта, киңәя. Татар әдәбияты Яңарыш идеологиясен үзенә нигез итеп ала һәм реализм юлына чыга. Халык тормышына йөз тоту үзәк урынны били бара. Сүз сәнгатендә проза һәм драматургия төрләре мәйданга чыга.* Әлеге үзенчәлекләр кайсы чор әдәбиятына хас? (2 балл)

Җавап: **Мәгърифәтчелек әдәбияты / XIX гасыр әдәбияты**

## II. Язма җавапка бәйле биремнәр (25 балл).

1. Татар мәгърифәтчелек әдәбияты. Мәгърифәтчелек әдәбиятына хас үзенчәлекләр (10 балл).

**9 сыйныф дәреслеге, Казан, 2016, Б. 49-53.**

2. Фатих Әмирхан иҗаты турынданиләр беләсез, аның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар? Үзенең әсәрләрендә ул нинди тема-проблемаларны күтәрә? Үзегез укыган бер әсәр мисалында аңлатыгыз (10 балл).

**9 сыйныф дәреслеге, Казан, 2016, Б. 76-78.**

3. Муса Җәлилнең «Кызыл ромашка» шигыреннән алынган өзектә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып языгыз (5 балл):

*Иртәнге таң нурыннан*
*Уянды ромашкалар.*
*Елмаеп, хәл сорашып,*
*Күзгә-күз караштылар.*

*Назлады җил аларны,*
*Тибрәтеп ак чукларын,*
*Таң сипте өсләренә*
*Хуш исле саф чыкларын.*

*Чәчкәләр, кәефләнеп,*
*Җай гына селкенделәр.*
*Һәм кинәт шунда гаҗәп*
*Бер яңа хәл күрделәр.*

*Ерак түгел моңаеп,*
*Утыра ромашка кызы,*

*Тик чуклары ак түгел,*
*Кан шикелле кып-кызыл.*

*Ромашкалар бар да ак,*
*Аерылмый бер-береннән;*
*Ничек болай бер үзе*
*Ул кызылдан киенгән?*

**Инверсия, антоним, метафора, сынландыру, эпитет һ.б.**

**III. Әдәби әсәргә анализ (10 балл).**

**Әсәрнең жанры – гражданлык лирикасы**

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2024-2025 уку елы) 10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 180 минут**
**Максималь балл – 55 балл**

**I. Тест биремнәре (10 балл).**

1. Сүз сәнгатендә тупланган тәҗрибәне буыннан-буынга күчерү (1 балл):
1) дәвамчанлык
2) **традиция**
3) яңачалык

2. Иҗат юнәлеше төшенчәсе (1 балл):
1) экспрессионизм
2) тәнкыйди реализм
3) **романтизм**

3. Көлке ситуациягә корылган, нигезендә көлке конфликт яткан драма жанры (1 балл):
1) драма
2) хикәя
3) **комедия**

4. Сюжет элементы (1 балл):
1) тәмсил
2) метонимия
3) **вакыйгалар үстерелеше**

5. Сүз сәнгатенә хас сыйфатларны, билгеләрне, теоретик төшенчәләрне өйрәнә торган фән (2 балл):

Җавап: **<u>әдәбият теориясе</u>**

6. Котб, Сәйф Сараи иҗатлары әдәбиятның кайсы чорына карый (1 балл):
1) **Алтын Урда чоры әдәбияты**
2) Казан ханлыгы чоры әдәбияты
3) Болгар чоры әдәбияты

7. Кол Шәрифнең «...Гафил торма», «И күңел, бил баглама...» әсәрләре кайсы жанрга карый (1 балл):
1) гражданлык лирикасы

2) **газәл**
3) дастан

8. *Риваятьләргә караганда, ул 1883 еллар тирәсендә Чулман буендагы шәһәрләрнең берсендә туган. Кайбер чыганакларда аның Кашан шәһәрендә тууы әйтелә. Әдипнең үлә вакытын XIII гасырның 30 еллар ахыры – 40 еллар башы дип билгелиләр. Ул башта Болгар мәмләкәтендә, соңыннан Харәземдә белем алган. Кушаматы Кол атамасы белән бәйләнгән. Хәзерге вакытта күп күчермәләре саклана торган данлыклы әсәр иҗат иткән.* Кем турында сүз бара? (2 балл)

Җавап: **<u>Кол Гали</u>**

**II. Язма җавапка бәйле биремнәр (25 балл).**

1. XIX гасырда реалистик әдәбият формалашу. Бу чор реалистик әдәбиятына хас үзенчәлекләр, авторлар (10 балл).

**10 сыйныф дәреслеге, 2016, Б. 181-182.**

2. Сәйф Сараи яки Габдулла Тукай иҗаты турынданиләр беләсез? Җавабыгызны үзегез сайлап алып, бер әдип иҗатына бәйле языгыз. Аның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар? Үзенең әсәрләрендә ул нинди тема-проблемаларны күтәрә? Үзегез укыган бер әсәр яки әсәрләр мисалында аңлатыгыз (10 балл)

**10 сыйныф дәреслеге, 2016, Б. 123-124 (С.Сараи) яки яңа дәреслек (Г.Тукай).**

3. Муса Җәлилнең «Чәчәкләр» шигыреннән алынган өзектә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып языгыз (5 балл):

*Барыгыз болынга, балалар!*
*Йөгерегез, уйнагыз, көлегез!*
*Елмайсын күреп шат аналар,*
*Юансын боеккан күңлегез.*

*Болында күп матур чәчәкләр,*
*Барсы да татлы хуш исләләр.*
*Нәркисләр, сөмбелләр һәм мәкләр,*
*Нәкъ сезнең ирнегез төсләләр.*

*Җил көйләп тирбәтә аларны,*
*Иркәли кояшның нурлары.*
*Алар бит изге Җир-ананың*
*Сөекле кызлары, уллары.*

*Бу җирдә күп булды сугышлар,*
*Янгыннар, явымнар, давыллар,*
*Киселде күп батыр тормышлар,*
*Янды зур калалар, авыллар...*

**Синоним, градация, инверсия, метафора, сынландыру, эпитет һ.б.**

**III. Әдәби әсәргә анализ (10 балл).**

**Әсәрнең жанры – гражданлык лирикасы**

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2024-2025 уку елы) 11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты- 180 минут**
**Максималь балл – 55 балл**

**I. Тест биремнәре (10 балл).**

1. Яшәүнең мәгънәсен эзләүче ялгыз шәхес фаҗигасе үзәктә яткан модернистик агым (1 балл):
1) **экзистенциализм**
2) тәнкыйди реализм
3) романтизм

2. Иҗат юнәлеше төшенчәсе (1 балл):
1) мәгърифәтчелек реализмы
2) **модернизм**
3) экспрессионизм

3. Драматургиянең бер жанр формасы. Үткен интрига, гадәттән тыш эмоциональлек, яхшылык белән явызлыкның кискен каршы куелуы, әхлакый үгет-нәсихәт өстенлек итә, музыка киң кулланыла (1 балл):
1) трагедия
2) драма
3) **мелодрама**

4. Сюжет элементы (1 балл):
1) градация
2) хронотоп
3) **эпилог**

5. Нindидер тарихи вакыйга, хәл, җәмгыятьтәге тәртип-мөнәсәбәтләр, хаксызлыкларга кагылышлы хис-кичереш сурәтләнгән лирик жанр (2 балл):

Җавап: **гражданлык лирикасы**

6. Фатих Хөсни, Муса Җәлил иҗатлары әдәбиятның кайсы чорына карый (1 балл):
1) XX йөз башы әдәбияты
2) Сугыштан соңгы еллар әдәбияты
3**) Бөек Ватан сугышы еллары әдәбияты**

7. «Хәят», «Авырган минутларда», «Иртә төшкән кар» шигырьләренең авторы (1 балл):

1) Муса Җәлил
2) **Хәсән Туфан**
3) Фатих Кәрим

8. *Тынгысыз җанлы, заман җилләренә сизгер шагыйрь җәмгыятьнең дөрес юлдан үсмәвен, гаделсезлекләрне күрә, йөрәк әрнүен «Ант» поэмасында шартлы, күчерелмә мәгънә, эзоп теле мөмкинлекләре ярдәмендә чагылдыра… Шул әсәре, ахыр чиктә, аны гаепләүләргә алып килә.* Кем турында сүз бара? (2 балл)

Җавап: **<u>Хәсән Туфан</u>**

## II. Язма җавапка бәйле биремнәр (25 балл).

1. Эпик төргә хас үзенчәлекләр, жанрлары. Үзегезнең фикерләрегезне әсәрләрдән мисаллар нигезендә дәлилләп барыгыз (10 балл).

Мисал өчен:

**Эпос грекча «сүз» мәгънәсен аңлата. Чөнки ул кешеләр тормышын-яшәешен, чынбарлыкны сөйләп бирә. Эпик төрне оештыручы нокта, нигез булып хикәяләү – персонажлар, аларның язмышы, эш-гамәлләре, холык-фигыле, алар тормышындагы хәлләр-вакыйгалар турында сөйләү тора. Эпоста вакыйгалар үзара сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә булып, әсәрләр урынны, вакытны, тышкы дөнья-тирәлекне һәм геройларның эчке кичереш-халәтен күрсәтәләр, күз алдына китереп бастыралар. Бу вакытта сурәтләү ярдәмгә килә. Язучы геройларның портретын, пейзажны, урынны, катнашучыларның халәтен, кәефе үзгәрүне һ.б. сурәтләп бирә, әйбер, табигать, хис-кичереш, кеше образлары тудыра. Эпоста образ – барыннан да элек шәхес, үзенең характеры, исеме, язмышы, кичерешләре берлегендә тасвирланган характер. Монда кеше образлары гадәти тормыштагыча: эш-гамәлләрдә, уй-фикерләрдә, теләк-омтылышларда сурәтләнә, төрле сыйфатлар, каршылыклар җыелмасы итеп күрсәтелә. Эпосның киңлеге, күләмлелеге, зурлыгы аңа кеше тормышы–язмышы тарихын да, характерларны да сыйдырырга, кешенең эчке, уй-хыял дөньясына үтеп керергә мөмкинлек бирә. Эпик әсәрдә тормыш-чынбарлык үзе алгы рәткә чыга. Ләкин әдип аны образлы сурәтли, үз хыялында яшәгән детальләр ярдәмендә җанландыра.**

**Эпоста сурәтләү предметы һәм сөйләүче вакыт ягыннан ераклаштырыла: сүз читтән торып һәм гадәттә өченче заттан алып барыла. Хикәяләүче элегрәк булган хәлләрне искә төшерүче кебек тәэсир калдыра. Ул – сурәтләнгән дөнья белән укучы арасында торучы, еш кына күзәтүче ролендәге герой. Төп жанрлары – хикәя, повесть, роман.**

2. Аяз Гыйләҗев яки Мөхәммәт Мәһдиев иҗаты турында ниләр беләсез? Җавабыгызны үзегез сайлап алып, бер әдип иҗатына бәйле языгыз. Аның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар? Үзенең әсәрләрендә ул нинди тема-проблемаларны күтәрә? Үзегез укыган бер әсәр яки әсәрләр мисалында аңлатыгыз (10 балл):

**11 сыйныф дәреслеге, 2017, Б. 129-130 (А.Гыйләҗев) яки яңа дәреслек (М.Мәһдиев)**

3. Муса Җәлилнең «Чәчәкләр» шигыреннән алынган өзектә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып языгыз (5 балл):

*... Сез назлап үбегез гөлләрне,*
*Хуш истән күңлегез ачылсын.*
*Җир бирде сезгә шат көннәрне,*
*Йотып тир, кан һәм яшь тамчысын.*

*Балалар, сез гөлләр үзегез,*
*Чыктыгыз калкып җир карныннан.*
*Һәм чәчәк аттыгыз, үстегез*
*Атагыз, агагыз каныннан.*

*Сез безгә шулкадәр кадерле,*
*Шулкадәр ягымлы, сөйкемле!*
*Ал таңы алдагы дәвернең*
*Йөзегездә чагыладыр шикелле.*

*Чәчәкләр, үсегез, чәчәкләр,*
*Дәрт биреп безнең шат күңелгә.*
*Сезгә бу шатлыклар, рәхәтләр*
*Бит җиңеп алынган гомергә*

**Синоним, градация, инверсия, риторик эндәш, чагыштыру, метафора, сынландыру, эпитет һ.б.**

## III. Әдәби әсәргә анализ (10 балл).

**Әсәрнең жанры – гражданлык лирикасы**